**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен башкара торган коммерциячел булмаган оешманы билгеләү турында**

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^3$ статьясы 3 пункты 10 пунктчасы, «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы 3 кисәге 2 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасының ихтыярыйлык мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасын Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен башкара торган коммерциячел булмаган оешма дип билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасының ихтыярыйлык мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге буларак түбәндәге юнәлешләрдә эшчәнлек алып бара дип билгеләргә:

хәйрия, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар һәм башка оешмалар белән берлектә Татарстан Республикасында ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү;

Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә булышлык күрсәтү инфраструктурасын үстерү;

ихтыярыйлык (волонтерлык) һәм хәйрия эшчәнлегендә катнашучыларга һәм әлеге эшчәнлекне оештыручыларга, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары вәкилләренә методик ярдәм күрсәтү, аларның компетенцияләрен үстерү һәм алар өчен уку-укыту программалары уздыру;

ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасын үстерү һәм киңрәк таныту, шул исәптән ихтыярыйлыкны (волонтерлыкны), хәйрия эшчәнлеген оештыручылар турында мәгълүматларның дөреслеген тикшерү;

федераль һәм төбәк проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыру, шулай ук муниципаль проектларны һәм ихтыярыйлыкта (волонтерлыкта) катнашучыларга башлангычларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтү;

ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә иң киң таралган юнәлешләрне, кызыксындыру факторларын ачыклау максатында тикшеренүләр уздыру;

Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлыкны үстерү, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга мәгълүмат, консультацияләр бирү, методик хезмәтләр комплексы күрсәтү, шулай ук ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә булышлык күрсәтү инфраструктурасын үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек алып бару;

программаларда, проектларда, чараларда катнашу һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Ихтыярыйлык үзәкләре ассоциациясе, «Игелек.рф» коммерциячел булмаган оешмалары һәм иҗтимагый үсеш институтлары яисә Яшьләр эшләре федераль агентлыгы соратулары буенча аларга тиешле аналитик мәгълүматны юллау.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге буларак «Татарстан Республикасының ихтыярыйлык мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы эшчәнлегенә законнарда каралган рәвешләрдә булышлык күрсәтү;

«Татарстан Республикасының ихтыярыйлык мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына эшчәнлек алып бару өчен субсидияләр бирү тәртибен расларга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына үз компетенцияләре чикләрендә Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге буларак «Татарстан Республикасының ихтыярыйлык мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы эшчәнлегенә законнарда каралган рәвешләрдә булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 10 ноябрь
№ 925